ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.08.2020 № 538

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 гыйнварындагы 30 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең аерым закон актларына эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең реестр моделен кертү өлешендә үзгәрешләр кертү турында 27.12.2009 елдагы 478-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 18.01.2009 ел, № 30 карары белән расланган Муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты стандартларына түбәндәге үзгәрешләр кертергә: 1.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү (1 нче кушымта); 1.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениясенең балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле учреждениесендә балаларга өстәмә белем бирү (2 нче кушымта):

Административ регламент 1нең 9.4 пунктындагы 2 пунктчасының 3 абзацын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.А. Газизуллин